МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

23.06.2023 Казан ш № 501

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 30 ноябрендәге 880 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында 14 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган гражданнарны укудан буш вакытында, эш эзләүдә кыенлыклар кичерә торган эшсез гражданнарны, урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм алган белем турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан башлап бер ел дәвамында эш эзли торган 18 яшьтән 25 яшькәчә булган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты гамәленең гражданнарның аерым категорияләренә кагылуы турында» 2022 елның 30 июнендәге 651 номерлы боерыгына үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 16 мартындагы 376 номерлы карарының 2 пунктына үзгәреш кертү турында» 2023 елның 29 маендагы 865 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 30 ноябрендәге 880 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында 14 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган гражданнарны укудан буш вакытында, эш эзләүдә кыенлыклар кичерә торган эшсез гражданнарны, урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм алган белем турында һәм квалификация турында документ

бирелгән датадан башлап бер ел дәвамында эш эзли торган 18 яшьтән 25 яшькәчә булган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты гамәленең гражданнарның аерым категорияләренә кагылуы турында» 2022 елның 30 июнендәге 651 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2023 елның 26 гыйнварындагы 41 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) үзгәреш кертеп, 1.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе яки Херсон өлкәсе территорияләрендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм торган урыны буенча мәшгульлек хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән Россия Федерациясе гражданнары;

2022 елның 30 сентябренә кадәр Донецк Халык Республикасы яки Луганск Халык Республикасы гражданлыгына ия булган гражданнар, Украина гражданнары һәм Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе яки Херсон өлкәсе территорияләрендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм торган урыны буенча мәшгульлек хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән, гражданлыгы булмаган затлар.».

2. Әлеге боерыкның гамәлдә булуы 2023 елның 10 июненнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

Министр ОТДЕЛ ДЕЛО-ПРОИЗВОДСТВА Э.Ә. Зарипова